Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Туембаш авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

2021 елның 12 ноябре №2

**«Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Туембаш авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2021 елның 26 ноябренә 11 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Туембаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Туембаш авылы, Ленин урамы, 87 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәчете бинасында үткәрергә.

2. 2021 елның 26 ноябренә 13 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Туембаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Туембаш авылы, Ленин урамы, 87 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәчете бинасында үткәрергә.

3. 2021 елның 26 ноябренә 14 сәгать 30 минутка Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Туембаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Туембаш авылы, Ленин урамы, 87 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәчете бинасында үткәрергә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: « I төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылардан һәм студентлардан (курсантлардан), Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Туембаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 1400 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Туембаш авылы Ленин урамы юлларына асфальт һәм вак таш җәю; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Туембаш авылы Заречная урамнары буенча юлларга вак таш җәю; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Туембаш авылы Ленин урамнары буенча юлларга вак таш җәю; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Ленин урамы буенча Парковка урыннарының вак таш түшәмнәрен урнаштыру һәм ремонтлау; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Ленин урамы буенча автомобиль күперен ремонтлау һәм урнаштыру; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Туембаш авылының урам юл челтәрен карап тоту, чапкыч һәм ягулык-майлау материаллары, запас частьлар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү;
- Туембаш авылында артезиан скважинасы өчен насос сатып алу;
- Туембаш авылы зиратын карап тоту, җиһазлар һәм инвентарь алу;
- Туембаш авыл мәдәният йортына видеокамера сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, сатып алу, урнаштыру)»?

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

6. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Туембаш авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Туембаш авыл җирлеге башлыгы: И. Ф.Гарипов